СОВЕТ
ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24.03.2022 г.Зеленодольск № 80

Зеленодольск шәһәре Советының аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Зеленодольск шәһәре Советының хокукый актларын актуальләштерү максатларында, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына туры китереп, Зеленодольск шәһәре Советының 2021 елның 17 декабрендәге 68 номерлы карары белән Зеленодольск шәһәре территориясендә муниципаль торак контроле турындагы нигезләмәне яңа редакциядә раслауга бәйле рәвештә, Зеленодольск шәһәре Советы **карар итте:**

1. Зеленодольск шәһәре Советы түбәндәге карарларының үз көчләрен югалтуын танырга:

- «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 7 сентябрендәге 301 номерлы;
- «Зеленодольск шәһәре Советының 2020 елның 7 сентябрендәге 301 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 3 июнендәге 42 номерлы.

2. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Зеленодольск шәһәре Хакиме,**
**Совет рәисе** **М.П. Афанасьев**

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ ГОРОДА ЗЕЛЕНОДОЛЬСКА ИНН 1648017849 КПП 164801001 ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ